ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында” 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 5 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) дүртенче абзацта “, хезмәтне саклау буенча инструктаж, эш урынында стажировка” сүзләрен төшереп калдырырга, “оештыра” сүзен “координацияли” сүзенә алмаштырырга;
б) бишенче абзацта “, хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрүне һәм хезмәтне саклау эшләрен оештыруның хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләренә туры килүен раслауны үткәрүне оештыра” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 статьяның унҗиденче абзацында “компенсацияләргә” сүзен “гарантияләргә һәм компенсацияләргә” сүзләренә алмаштырырга, “авыр эшләрдә,” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 7 статьяда:
а) өченче өлештә “Авыр эшләр,” сүзләрен төшереп калдырырга, “компенсацияләр һәм ташламалар” сүзләрен “гарантияләр һәм компенсацияләр” сүзләренә алмаштырырга;
б) җиденче өлештә “авыр эшләрне,” сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 8 статьяда:

а) исемдә “Авыр эшләргә,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) беренче өлештә “Авыр эшләрдә,” сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 10 статьяның өченче абзацында “җитештерү объектларын төзүне һәм реконструкцияләүне проектлаганда, яңа техниканы җитештергәндә һәм гамәлгә керткәндә, яңа технологияләр һәм җиһазларны керткәндә эш урыннарына” сүзләрен “хезмәт шартларына” сүзләренә алмаштырырга;

6) 14 статьяның икенче өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

“хезмәтне саклау белән идарә итү системасын булдыруны һәм аның эшләвен;”;

б) өченче – тугызынчы абзацларны тиешенчә дүртенче – унынчы абзацлар дип санарга;

в) унынчы абзацны унберенче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“хезмәт шартларын махсус бәяләү турында законнар нигезендә хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруны;”;

г) унберенче һәм уникенче абзацларны тиешенчә уникенче һәм унөченче абзацлар дип санарга;

д) унөченче абзацны ундүртенче абзац дип санарга һәм анда “һәм аларга тиешле компенсацияләр” сүзләрен “, аларга бирелә торган гарантияләр, аларга тиешле компенсацияләр”сүзләренә алмаштырырга;

е) ундүртенче – егерме өченче абзацларны тиешенчә унбишенче – егерме дүртенче абзацлар дип санарга;

7) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле бишенче өлеш өстәргә:

“Дәүләт хезмәтне саклау өлкәсендә белгечләр әзерләүне тәэмин итә.”;

8) 17 статьяның беренче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

9) 23 статьяның дүртенче өлешендә “, шул исәптән производствода бәхетсезлек очрагы алдыннан булган чорда,” сүзләрен төшереп калдырырга, “авыр эш, зарарлы һәм (яисә) хәвефле хезмәт шартларында эшләгән өчен хезмәткәрләргә компенсацияләр” сүзләрен “зарарлы һәм (яисә) хәвефле хезмәт шартларында эшләгән өчен хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр” сүзләренә алмаштырырга, “хезмәт шартлары буенча хезмәт урыннарына аттестация үткәрү сыйфатын” сүзләрен “хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын” сүзләренә алмаштырырга, “, җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыру, яңа техника җитештерү һәм гамәлгә кертү, яңа технологияләрне гамәлгә кертү проектларының хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләренә туры килүен” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 23 июле
№ 60-ТРЗ